**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**" 14 "ноябрь 2018 ел** **№ 90**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 88, 89, 90 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын (1 нче кушымта) хупларга.
2. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында» Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2 нче кушымта нигезендә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен раслау турында"

   3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
   1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
   2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Караталга авылы, Күпер урамы, 5;
   3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14;
   шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

1. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы

Иске Казиле авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге”
Советы рәисе И.Х.Сәгдиев

2018 елның 14 ноябрендәге
ТР Кама Тамагы муниципаль
районы Иске Казиле авыл җирлеге
Советының " Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге
Уставына Үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”
90 номерлы карарына1 нче номерлы
кушымта

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге” Муниципаль берәмлегенең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 8 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә::

"17) 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе «Кулланучылар хокукларын яклау турында"гы Законда каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.».

2. 32 статьяның 6 пунктындагы 1 пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

"1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, Профсоюзда катнашудан тыш, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; гамәлгә куючы (акционер) булган муниципаль берәмлек идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә; федераль законнарда каралган башка очраклар;».

3. 54 статьясына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

1992 елның 7 февралендәге «Кулланучылар хокукларын яклау турында"гы 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.».